**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Советы КАРАРЫ**

**26 август 2019 ел** **№ 210**

**2008 елның 26 июнендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 180 номерлы Карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль милкен биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турында”гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2008 елның 26 июнендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль милеген биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 180 номерлы Карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль милкенә ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе турында”гы Нигезләмәгә, 3.1 пунктның 3.1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

“3.1. Муниципаль мөлкәт (җирле бюджет һәм бюджеттан тыш фондлардан тыш) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль Башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә муниципаль милек реестрында мәҗбүри исәпкә алынырга тиеш.”.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы урынбасары Г.Ә. Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе Н.А. Вазыйхов**